ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 452-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 452-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2072-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында**

**1 статья**

Үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4);

2) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 елның 24 июнендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 6);

3) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 16 декабрендәге 128-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш );

4) «Икътисади үсеш өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 27 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4);

5) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 9 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1);

6) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 30 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш );

7) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 20 июлендәге 61-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш );

8) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш);

9) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» 1996 елның 28 мартындагы 483 карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4).

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Закон проекты тарафыннан «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба - 482 номерлы Закон) үз көчен югалткан дип тану күздә тотыла.

482 номерлы Законны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты үткәргән мониторинглау нәтиҗәсендә 482 номерлы Законның кайбер нигезләмәләренең актуаль булмавы һәм килештерелмәве, «Нәселле терлекчелек турында» 1995 елның 3 августындагы 123-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларының кабатлануы ачыкланды, аның күп кенә нигезләмәләре үз көчен югалтты дип танылды.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә нәселле терлекчелекне җайга салучы субъект составы үзгәрде, нәсел эше өлкәсендәге функцияләр вәкаләтле учреждениедән тапшырылды һәм хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Нәсел эшенә дәүләт ярдәме федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар, нәселле терлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган «2013-2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык – төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәүләт программасы нигезендә гамәлгә ашырыла. Субсидияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 елның 30 июнендәге 514 номерлы һәм «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 елның 31 маендагы 397 номерлы карарлары белән регламентташтырыла. Моңа бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме тәртибен өстәмә билгеләү кирәкми.

Шулай итеп, күрсәтелгән өлкәдә барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләр җитәрлек хокукый җайга салуга ия.

Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының нәселле терлекчелек өлкәсендә федераль законнарда каралган вәкаләтләре аз булуны, шулай ук югарыда әйтелгән шартларны исәпкә алып, нәсел эше мәсьәләләрен закон дәрәҗәсендә хокукый җайга салу максатка ярашлы түгел. Моңа бәйле рәвештә закон проекты белән 482 номерлы Законны һәм аңа үзгәрешләр кертү турында актларны үз көчләрен югалткан дип тану күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының берничә карарына һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыкларына аларда «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законына сылтамаларны төшереп калдыру өлешендә төзәтмәләр кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.